**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2024лның 22 ноябре** **90 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге составына керүче Олы Кабан торак пунктында (Һади Такташ ур., Александр Пушкин ур., Михаил Лермонтов ур., Рудольф Нуриев ур., Гавриил Державин ур., Профсоюз ур.,территориясе өлешендә) гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 16 ноябрендәге «2025 елда үзара салым кертүгә Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пункты территориясендә (Һади Такташ ур., Александр Пушкин ур., Михаил Лермонтов ур., Рудольф Нуриев ур., Гавриил Державин ур., Профсоюз ур.,территориясе өлешендә)яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидларны исәпкә алмыйча, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны-

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Олы Кабан авылы):
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Кооператив урамындагы чокырда агач кисү, тамыр системасын бетерү);
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү эшләре өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

-сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 117 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында 60 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пунктында (Һади Такташ ур., Александр Пушкин ур., Михаил Лермонтов ур., Рудольф Нуриев ур., Гавриил Державин ур., Профсоюз ур., территориясе өлешендә ) гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пункты территориясендә (Һади Такташ ур., Александр Пушкин ур., Михаил

Лермонтов ур., Рудольф Нуриев ур., Гавриил Державин ур., Профсоюз ур., территориясе өлешендә) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 3000 сум күләмендә кертергә. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Олы Кабан авылы):

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Кооператив урамындагы чокырда агач кисү, тамыр системасын бетерү);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү эшләре өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ И.Г. Шәрәфиев

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Олы Кабан
авыл җирлеге Советы рәисе: _________________ И.Г. Шәрәфиев